КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 ноябрь г.Казань № 1037

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 14 май, 383 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы

авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 14 май, 383 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 21 май, 415 нче; 2020 ел, 19 июнь, 505 нче; 2020 ел, 7 август, 661 нче; 2020 ел, 10 октябрь, 919 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

2 нче пунктның икенче абзацында «2020 елның апрелендә – сентябрендә» сүзләрен «2020 елның апрелендә – октябрендә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына субсидияләр бирү тәртибендә:

1.4 нче пунктта «2020 елның апрель – сентябрь» сүзләрен «2020 елның апрель – октябрь» сүзләренә алыштырырга;

2.3 нче пунктның беренче абзацында «2020 елның 30 сентябреннән» сүзләрен «2020 елның 31 октябреннән» сүзләренә алыштырырга;

4.3 нче пунктның беренче абзацында «30 октябренә» сүзләрен «30 ноябренә» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин